Республика Татарстан
Руководитель Исполнительного комитета Багряжского сельского поселения Заинского муниципального района

ул. Центральная, д.47а с. Средний Багряж, Заинский район, 423516

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Баграж авыл җирлегенең башкарма комитеты җитәкчесе

Үзәк урам, 47а йорт, Урта Баграж авылы, Зәй районы, 423516

Телефон, факс 64-3-42. Электронный адрес: Bagr.zai@tatar.ru, сайт: www.Bagrazh.moy.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.10.2020 ел**

**КАРАР**
**№ 20**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 20 июнь 24 нче номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 2020 елның 07 февралендәге 16 номерлы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы боерыгы нигезендә, Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 20 июнь 24 нче номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты карарына (Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитетының 10.12.2019 елның 42 номерлы, 12.08.2020 елның 18 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктта:

а) 1 пунктчада «Инструкциянең 11 пункты белән» сүзләрен «Инструкциянең 11, 12 пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктчаның икенче абзацында «(Инструкциянең 15 пункты)» сүзләрен «(Инструкциянең 22 пункты)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 2.11.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) мондый гамәлне башкару Россия Федерациясе законнарына каршы килә;

2) гамәл башка җирлек, муниципаль, шәһәр округы яисә муниципаль район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты (мирас буенча мөлкәтне саклау чараларын кабул итүгә карата) яисә нотариус тарафыннан башкарылырга тиеш;

3) нотариаль гамәл кылу турында үтенеч белән хокукка сәләтсез граждан яисә тиешле вәкаләтләре булмаган вәкил, яшәү яисә тору урыны буенча теркәлүе булмаган граждан мөрәҗәгать итү;

4) ышанычнамә Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;

5) нотариаль гамәл башкару өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;

6) нотариаль гамәл кылу өчен тапшырылган документларда бәян ителгән фактлар, раслану Россия Федерациясе законнары нигезендә таләп ителгән очракта, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган.».

1.3. 2.11.3 пунктта «Инструкциянең 19 пункты белән» сүзләрен «Инструкциянең 27 пункты белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы рәсми сайтының “Авыл җирлекләре” бүлегендә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

**Башкарма комитет җитәкчесе** **П.Н. Минеев**